**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**10 октябрь 2019 ел** **№ 243**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының социаль-икътисадый, интеллектуаль һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән, хезмәттә, укуда аеруча зур уңышларга ирешүче гражданнарны һәм хезмәт коллективларын, дәүләт һәм һөнәри бәйрәмнәр, әһәмиятле һәм истәлекле даталар белән бәйле рәвештә бүләкләү максатыннан, Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мактаулы исемнәре һәм бүләкләре турында» Нигезләмәне раслау хакында» Нурлат муниципаль районы Советының 2006 ел, 28 гыйнвар, 31/1 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин

Нурлат муниципаль район
Советының 2019 елның 10
октябрендәге 243 номерлы
карарына 1 нче кушымта

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Нурлат муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы (алга таба - Мактау грамотасы) районның иминлеген тәэмин итүгә һәм халыкның тормыш дәрәҗәсен арттыруга, югары һөнәри осталык һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен гражданнар һәм предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар коллективларын бүләкләү формасы булып тора.

1.2. Мактау грамотасы икътисад, җитештерү, авыл хуҗалыгы, социаль өлкә, мәдәният, тәрбия һәм белем бирү, сәламәтлек саклау, спорт һәм физик культура, әйләнә-тирә мохитне саклау, законлылык, хокук тәртибе, җәмәгать куркынычсызлыгы, Нурлат муниципаль районының абруен һәм дәрәҗәсен күтәрү буенча иҗтимагый һәм муниципаль эшчәнлек өлкәсендә гражданнар, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар коллективларының зур хезмәтләрен тану билгесе буларак тапшырыла.

1.3. Мактау грамотасы белән бүләкләү район башлыгы инициативасы белән, шулай ук тиешле оешма, предприятие яки учреждение җитәкчесе тәкъдиме буенча башкарыла.

1.4. Гражданнарның шәхси мөрәҗәгатьләре буенча бүләкләү үткәрелми.

1.5. Бүләкләү өчен бирелә торган эш стажы әлеге оешмада, предприятиедә яки учреждениедә кимендә 3 елдан да ким булырга тиеш түгел (аерым очракларда күрсәтелгән сроклардан кимрәк).

1.6. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнары гамәлгә куючы булып торган муниципаль бюджет, казна һәм автоном учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә хезмәт эшчәнлеген алып баручы затларга, бүләк бер тапкыр бирелә.

Башка оешма җитәкчеләренә үз хезмәткәрләренә Мактау грамотасы белән бүләкләгәндә премияне оешма чаралары хисабыннан бирү тәкъдим ителә.

## 2. Мактау грамотасы белән бүләкләү турында документлар тапшыру тәртибе

2.1. Бүләкләү турындагы документлар Нурлат муниципаль районы башлыгы исеменә рәсмиләштерелә, вазифаи затларны һәм оешмаларны Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы үтенечнамәне һәм тәкъдимне үз эченә ала, оешма җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм мөһер белән таныклана. (Кушымта 1).

2.2. Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдим итү әлеге оешмада каралган бүләкләрне тапшырганнан соң гамәлгә ашырыла.

2.3. Нурлат муниципаль районы башлыгына бүләкләү датасына кадәр бер ай кала бүләкләү турындагы тәкъдим кертелә.

2.4. Нурлат муниципаль районы алдындагы яңа казанышлары өчен бары алдагы бүләкләнүдән соң 5 ел узгач кына яисә Нурлат муниципаль районы

файдасына, шулай ук район башлыгы инициативасы буенча башкарылган аерым казанышлар өчен генә Мактау грамотасы белән кабат бүләкләү мөмкин.

2.5. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы карар Нурлат муниципаль районы башлыгы карары белән рәсмиләштерелә, ул Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында басыла.

**3. Мактау грамотасы белән бүләкләү турында документларны әзерләү, исәпкә алу һәм саклау тәртибе.**

3.1. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы карар Нурлат муниципаль районы башлыгы карары белән рәсмиләштерелә, ул Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында басыла.

3.2. Бүләкләнүчеләрне исәпкә алуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының оештыру бүлеге гамәлгә ашыра.

3.3. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы карар ике дәүләт телендә (татар һәм рус телләрендә) рәсмиләштерелә.

**4. Мактау грамотасын тапшыру тәртибе.**

4.1. Мактау грамотасы Нурлат муниципаль районы башлыгы яки аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан тантаналы шартларда тапшырыла.

4.2. Мактау грамотасы Нурлат муниципаль районы башлыгының бүләкләү турындагы карары чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

4.3. Бүләкләнүчедән Нурлат муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасын алу, бүләкләр буенча район комиссиясе тәкъдиме нигезендә, тиешле нигезләнгәннән (дөреслек, нигезсез бүләкләү яисә башка сәбәпләр буенча бүләкләү билгеләнгәннән соң) соң гына башкарылырга мөмкин. Мактау грамотасын тартып алу турындагы карар Нурлат муниципаль районы башлыгы тарафыннан кабул ителә.

4.4. Бүләкләүне гамәлдән чыгару турында карар кабул ителгән затка тапшырылган Мактау грамотасы Нурлат муниципаль районы Советы аппаратына кире кайтарылырга тиеш.

4.5.Мактау грамотасы югалганда дубликат бирелми.

4.6. Бүләкләнүче вафат булган очракта, аңа исән чагында тапшырылып өлгермәгән Мактау грамотасы мәрхүм бүләкләнүченең гаиләсенә тапшырыла.

Нурлат муниципаль район
Советының 2019 елның 10
октябрендәге 243 номерлы
карарының 1 нче кушымтасына
кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләү турында тәкъдим

1.ФИАи_______________________________________________________________

2. Вазыйфа, эш урыны ____________________________________________

__________________________________________________________________

(предприятие, учреждение, оешманың төгәл исеме)

3. Туган көне _______________________________________________

(көн, ай, ел)

4. Коллективның яки бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затның казанышлары һәм уңышлары төгәл күрсәтелгән кыскача характеристикасы
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________

5. Булган бүләкләр (предприятие, тармак, район дәрәҗәсендә)________________________________________________
__________________________________________________________________

6. Тәкъдим ителгән бүләкләү формулировкасы (Мактау грамотасы тексты)________________________________________________________
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________

7.Кандидатураны тәкъдим итүче
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________
(предприятие, учреждение, оешма җитәкчесе, хезмәт коллективы җыелышы)

_____________________ "___" ________________ 20__ ел

(Ф.И.А.и, имза)